| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФЕДОРОВСКИЙАВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

5.07. 2023е. Федоровский ав. №23

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлеге ягыннан капиталь инвестицияләрне яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе турында» 16.12.2021 №14 номерлы Федоровский авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә капиталь кертемнәрне яклау һәм хуплау турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»28.06.2022 елның 28 июнендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге ягыннан капиталь инвестицияләрне яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе турында» 16.12.2021 №14 номерлы Федоровский авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәнге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктта:

6 нчы пунктчада «транспорт салымы», һәм «,автомобильләргә җиңел һәм мотоциклларга акцизлар» сүзләрен чыгарырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча белән тулыландырырга:

«10) проектны гамәлгә ашыручы оешманың капиталь кертемнәрне яклау һәм хуплау турында килешү төзелгәннән соң өч ел эчендә салым мониторингы формасында салым контроленә күчү бурычы.»;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы авыл җирлегенең https:// fedor-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Ф.Ф.Зайнуллин